**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“13” ноябрь 2025 ел. № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль Законның 45, 69 статьялары нигезендә, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегенең Югары Сәрдә торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә мунисипаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр баликъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк граҗданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, мәхсус хәрби операциядә һәләк булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә узара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әхәмияткә ия булган тәбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Югары Сәрдә авылы территориясен чистарту (агачлар һәм куаклар кисү, үләннәр чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

2) Ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Югары Сәрдә авылы зираты территориясен чистарту (агач һәм куакларны кисү, үләннәрне чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3) Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен скважина бораулау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); су җыю җайланмалары сатып алу)).

4) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Югары Сәрдә авылының Алмаш, Тургай, Яшеллек урамнарындагы урам юлларын ремонтлау (вак таш сатып алу һәм салу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегенең Югары Сәрдә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Югары Сәрдә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы Хуснутдинов Р.Р.